**Җәмгыять белеме буенча олимпиада**

**10-11 нче сыйныфлар.**

**Биремнәрне үтәү өчен 3 сәгать вакыт бирелә.**

**Эш вакыты – 180 мин**

**1. Лингвистик конструктор. Бирелгән сүзләрдән төшенчәнең билгеләмәсен төзегез һәм язып куегыз. Түбәндә сүз алып барыла торган төшенчәне атагыз.**

1.1. Иң минималь, ихтыяҗларын, дип табылган, кешегә, канәгатьләндерү өчен, фәнни яктан караганда, кирәкле товарлар, хезмәт күрсәтүләр, һәм, җыелмасы

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

1.2. Вазифаларны башкарган, махсус тәртибе, иң югары, судта тикшерүнең, затларның, җинаятьләре турындагы эшләрне, һәм, җаваплылыкка тарту.

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

**2. Сорауга җавап бирегез. Әгәр сезнең җавабыгыз түбәндәге гыйбарә белән туры килсә “әйе”, туры килмәгән очракта “юк” дип билгеләгез.**

14 яшьтән алып 18 яшькәчә балигъ булмаганнар мөстәкыйль рәвештә ата-ана рөхсәтеннән башка:

2.1. Үзенең эш хакы, стипендиясе һәм башка керемнәре белән эш итәргә хокуклы.

2.2. Фән, әдәбият яисә сәнгать әсәре, уйлап табу хокукын тормышка ашырырга хокуклы.

2.3. Кредит учреждениясенә кертемнәр кертергә һәм алар белән эш итәргә хокуклы.

2.4. Иҗтимагый яшьләр оешмаларында катнашырга хокуклы.

2.5. Көнкүрештә вак алыш-бирешләр башкарырга хокуклы.

2.6. Никахлашырга, өйләнергә хокуклы.

2.7. Сайлауларда катнашырга хокуклы.

2.8. Судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Җавап:

| **2.1** | **2.2** | **2.3** | **2.4** | **2.5** | **2.6** | **2.7** | **2.8** |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |

**3. Сорауларга җавап бирегез. Дөрес җавапның астына сызып куегыз.**

3.1. Постиндустриаль җәмгыятькә нинди билгеләр хас?

1) сәнәгать революциясенең тәмамлануы

2) хуҗалыкның үзләштерүче төре

3) электрон массакүләм аралашу чараларының үсүе

4) коллективның югары бәяләнүе

3.2. Кешенең социаль асылы белән аның ихтыяҗлары нәрсәгә бәйләнгән?

1) үз-үзеңне танып белүгә

2) үз-үзеңне саклауга

3) физик активлыкка

4) уңайлы торакка

3.3. Базар шартларында җитештерүче өчен нәрсә файдалы?

1) товарларны үзләренә (шәхси) куллану өчен җитештерү

2) продукциягә бәяләрнең дәүләт тарафыннан билгеләнүе

3) җитештерелүче продукция берәмлегенә чыгымнарны киметү

4) төп җитештерү ресурсларын дәүләткүләм өләшү

3.4. Гражданнарга бушлай медицина ярдәме күрсәтү дәүләтнең нинди икътисади функциясен үтәү үрнәге булып тора?

1) халыкның керемнәре үсүне тәэмин итү

2) базар мөнәсәбәтләрен җайга салу

3) икътисадның тотрыклы үсешен тәэмин итү

4) иҗтимагый байлыклар җитештерү

3.5. Ачык хокук (публичное право) турында түбәндәгечә фикер йөртү дөресме?

А. Ачык хокук дәүләтнең гомуми мәнфәгатьләрен саклый.

Б. Ачык хокук аерым шәхесләрнең мәнфәгатьләрен канәгатьләндерү һәм яклауга юнәлдерелгән.

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) икесе дә дөрес түгел

3.6. Хәзерге Россия җәмгыятенең социаль стратификациясе нәрсәдә күренә?

1) җәмгыятьне төрле социаль төркемнәргә бүлгәләүдә

2) иҗтимагый тотрыклылыкны югалтуда

3) гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен киңәйтүдә

4) дәүләтнең аз тәэмин ителгән халык катлауларына булышлык итүендә

**4. Рәттәге артык элементны табыгыз.**

4.1. 1) РФ Югары Суды; 2) РФ Конституцион Суды; 3) Конституцион Җыелыш; 4) РФ Югары Арбитраж Суды

Җавап: ___________

4.2. 1) Мәдәни тормышта катнашу хокукы 2) Гражданлыкка хокук 3) Берләшү хокукы 4) Дәүләт хезмәтенә бертигез керү хокукы

Җавап: ___________

4.3. 1) Территория 2) Хакимият 3) Хокук 4) Милләт 5) Салымнар
Җавап: __________

**5. Курсив белән билгеләнгән урынны җәмгыять белеме термины белән алыштырыгыз.**

5.1. Соңгы вакытларда күп милләтләр арасында үз туган телләренә игътибар кимү, башка милләт вәкилләре белән никахка керү *этник йотылу* процессларын көчәйте.
Җавап: _______________________

5.2. Бүгенге көндә Европа илләрендә бара торган *күпсанлы кешеләрнең күченеп килүе* процесслары хакимият белән беррәттән төп халыкны да әлеге сәясәт сферасында яңа үзгәрешләр кертергә этәрде.
Җавап: _______________________

5.3. Европа һәм АКШ тарафыннан каралган санкцияләр Россиядәге *икътисад тармакларына кертелгән капиталның* күләмен шактый киметте.
Җавап: _______________________

**6. Түбәндәге икътисади мәсьәләләрне чишегез.**

6.1. Бу елда реаль тулай эчке продукт 2500 миллиард доллар тәшкил итте, ә аннан алдагы елда 2000 миллиард доллар иде. Бу елда икътисади күтәрелеш ничә процент булачак.
Җавап:

6.2. “Юмарт” фирмасы товар ассортиментын киңәйтү исәбенә җитештерүне арттырырга булды. Продукция эшләп чыгару түбәндәге гомуми чыгымнарны таләп итте: бина өчен аренда – 100 мең сум, чимал – 400 мең сум, эш хакы – 100 мең сум, кадрлар әзерләү – 20 мең сум, ягулык – 20 мең сум, транспорт

хезмәтләре – 10 мең сум. Даими һәм алмашучан чыгымнар суммасын исәпләп чыгарыгыз.

Җавап:

**7. Түбәндәге ситуацияләрне хокук нормалары күзлегеннән чыгып анализлагыз.**

7.1. Балигъ булмаган кыз туганнан туган апасы (тётя) тәрбиясендә (попечениясендә) иде. 18 яшь тулганчы ук әлеге кыз кияүгә чыгарга уйлады һәм апасына кияүгә чыкканнан соң аның тәрбиясенә мохтаҗ булмавын белдерде. Апасы каршы килеп, попечение балигъ булганга хәтле дәвам итүен искәртте һәм, әгәр кызның попечениядән котыласы килсә, аңа опека һәм попечительлек органнарына мөрәҗәгать итәргә кирәклеген белдерде.

**Әлеге ситуациядә кем хокуклы? Үз җавабыгызны аңлатыгыз.**

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

7.2. 16 яшьлек яшүсмер эшкә урнашу теләге белән машиналар төзәтү остаханәсенә килә. Үзе белән ул паспорт, хәрби теркәлү турындагы таныклык һәм эшкә урнашу гаризасын алып килә. Ләкин остаханә хуҗасы медицина тикшерүеннән һәм тиешле белешмәдән башка аның белән килешү төзү хокуклыгы булмавын белдерде.

**Бу очракта остаханә хуҗасы хокуклымы? Үз җавабыгызны аңлатыгыз.**

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

___________________________________________

**8. Таблицаны тутырыгыз.**

Законнар иҗат итү процессы берничә төп этаптан яисә стадиядән тора. Калган ике стадияне язып бетерегез.

| |
|---|
| 1. Дәүләт Думасына закон проектын кертү |
| 2. Дәүләт Думасында закон проектын тикшерү |
| 3. Дәүләт Думасында законны кабул итү |
| 4. |
| 5. |

**9. Төшеп калган сүзләрне языгыз.**

9.1. Икътисади циклның дүрт фазасы бар:

А) Икътисади күтәрелеш Б) __________________ В) Депрессия

Г) ___________________

9.2. Менеджментның дүрт функциясен аералар:

А) Оештыру Б) Планлаштыру В) ________________ Г) __________________

**10. Татарстан Республикасының Дәүләт Конституциясе 7 бүлектән тора. Әлеге бүлекләрне хронологик тәртиптә урнаштырыгыз.**

1) Дәүләт хакимияте оештыру.

2) Конституцион төзелеш нигезләре

3) Кеше һәм гражданнарның төп хокуклары, ирекләре һәм бурычлары

4) Җирле үзидарә

5) Административ-территориаль төзелеш

6) Дәүләт символлары һәм Татарстан Республикасы башкаласы

7) Татарстан Республика Конституциясен кабул итү тәртибе һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү

Җавап: ___________________________

**11. Түбәндә китерелгән текстны укып чыгыгыз, анда кайбер сүзләр төшереп калдырылган. Тәкъдим ителгән исемлектән сүзләрне буш калган урыннарга язып куярга кирәк.**

«Галимнәр диннәрнең берничә классификациясен булдырдылар. Аларның иң гадие - диннәрне өч төркемгә берләштерү. Примитив ыру-кабилә ышанулары, мәсәлән, __________(1). Алар __________(2) барлыкка килде, ләкин вакытлар узу белән кешеләр аңыннан юкка чыкмадылар, ә сакланып калдылар һәм бүгенгәчә катлаулырак диннәр белән бергә яшиләр. Аларда күпсанлы__________(3) бар. Аерым милләт-дәүләтнең бөтен яшәешенең асылы булган милли-дәүләт диннәре бар, мәсәлән _________(4). Милли-дәүләт чикләрен үтеп чыгучы һәм бөтен дөньяда күпсанлы тарафдарлары булган дөнья диннәре, дөньяда алар өчәү: ____________(5), христианлык һәм ислам. Барлык диннәрне ике зур төркемгә берләштерергә була:_____________(6), ягъни Аллаһның берлеген танучылар, һәм _____________(7) күп аллаларны танучылар.

Исемлектәге сүзләр баш килештә, берлек санда бирелгән. Сүзләрне, бушлыкны тутырып, бер-бер артлы сайлап алыгыз. Китерелгән исемлектә сүзләрнең текстка төшерелгәннәрдән күбрәк булуына игътибар итегез.

А) монотеизм

Ә) политеизм

Б) борынгы

В) культ

Г) буддизм

Д) индуизм

Е) хорафат, юк-барга ышану

Ж) миф

З) православие

И) тотемизм

**Түбәндәге таблицада бушлыкларның саннары күрсәтелгән. Һәр сан астына үзегез сайлап алган сүзләргә туры килгән хәрефләрне язып куегыз.**

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |

**12. Сезнең алдыгызда таблица. Беренче баганада латин яисә грек төшенчәләрнең турыдан-туры тәрҗемәсе. Икенче баганада әлеге төшенчәләр белән бәйләнгән иҗтимагый күренешләр күрсәтелгән. Таблицага төшенчәләрне һәм аларның мәгънәсен язып тутырып бетерегез.**

| Латин яисә грек төшенчәсенең тәрҗемәсе | Иҗтимагый күренешләр | Төшенчәләр һәм аларның мәгънәсе |
|---|---|---|
| «Сабырлык, түземлек» | Социаль мөнәсәбәтләр | |
| «Җайлашу» | Социальләшү | |
| “Халәт, хәл” | Иҗтимагый мөнәсәбәтләр | |

| | | |
|---|---|---|
| «Таратылырга тиешле” | Идеология | |
| “Аерым” | Милли мөнәсәбәтләр | |
| “Ул да түгел, башка да түгел” | Дәүләтнең тышкы сөясәте | |

**13. “Хокук” төшенчәсенең төрле мәгънәләре һәм аларның мөһим билгеләре арасындагы тәңгәллекне билгеләгез: беренче баганада бирелгән һәр позициягә икенче баганада тәңгәл килүче позицияне сайлап алыгыз.**

МӨҺИМ БИЛГЕЛӘР

А) хокук фәнен социаль нормаларның аерым системасы буларак өйрәнү

Ә) кеше һәм гражданинның хокукына регламент билгеләү

Б) канун бозуга каршы көрәш чараларын билгеләү

В) дәүләтнең һәм хокукның асылын теориягә нигезләп дәлилләү

Г) дәүләт һәм хокук тарихын өйрәнү

ТӨШЕНЧӘНЕҢ МӘГЪНӘСЕ

1) фән буларак хокук

2) иҗтимагый мөнәсәбәтләр буларак хокук

Сайлап алынган саннарны таблицага язып куегыз.

| А | Ә | Б | В | Г |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

**14. Җәмгыять белеме төшенчәләренә аңлатма бирегез.**

1) Импичмент –

2) Маргинал –

3) Матриархат -

4) Нуклеар гаилә –

5) Сальдо –

**15. Түбәндә китерелгән җәмгыять моделләре өчен демографик үсешкә хас закончылыкларны билгеләгез. Таблицага җавапка туры килгән тәртип саннарын языгыз.**

| 1 модель | 2 модель | 3 модель |
|---|---|---|
| | Күчү (переходное) җәмгыяте | |
| Туулар һәм үлемнәрнең күп булуы | | |
| | | Халык саны әкрен яисә бөтенләй үсми |

1. Туулар һәм үлемнәрнең аз булуы. 2. Традицион җәмгыять. 3. Халык саны кискен арта. 4. Халык саны акрын үсә. 5. Модернизацион җәмгыять 6. Туулар күп, үлемнәр аз.

**16. Түбәндә тәкъдим ителгән өземтәләрнең <u>берсен</u> сайлап алыгыз һәм күтәрелгән мәсьәлә буенча үз фикерегезне (карашыгызны, мөнәсәбәтегезне) бәян итегез. Үз карашыгызны нигезләү өчен <u>дәлилләр</u> китерегез.**
**Биремне үтәгәндә җәмгыять белеме курсыннан алган белемнәрегезне, туры килгән төшенчәләрне, шулай ук иҗтимагый тормыш фактларыннан һәм үз тормыш тәҗрибәгездән файдаланыгыз.**
**Темалар:**

1) «Кешегә рухи зат буларак, Җирдә хокуктан тыш яшәү мөмкин түгел» (И.А. Ильин).
2) «Фәлсәфә - ул чишеп булмастай мәсьәләләргә аз аңлаешлы җаваплар бирү» (Г.Б. Адамс).

3) «Кем вәгъдә биргәндә сак эш итә, аны үтәвен дә төгәл үти» (Ң.Ң.Руссо).

4) «Сәүдәнең бер генә халыкны да бөлгенлеккә төшергәне юк әле» (Б.Франклин).

5) «Матурлык күп көч түгеп өйрәнгәннән соң гына, ә начарлык көч түкмичә, үзеннән-үзе дә өйрәнелә» (Демокрит).

6) «Камиллектән курыкма, син аңа беркайчан да ирешә алмаячаксың» (С.Дали).